КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 ноябрь г.Казань № 1459

Кластерларда катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шулай ук сәнәгать парклары, технопарклар резидентларына комплекслы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Кластерларда катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шулай ук сәнәгать парклары, технопарклар резидентларына комплекслы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 11 ноябрь, 1459 нчы
карары белән расланды

Кластерларда катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шулай ук сәнәгать парклары, технопарклар резидентларына комплекслы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасындагы «2018 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасының «Кластерларда катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шулай ук сәнәгать парклары, технопарклар резидентларына комплекслы хезмәтләр күрсәтү» чараларын гамәлгә ашыру кысаларында кластерларда катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шулай ук сәнәгать парклары, технопарклар резидентларына комплекслы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидия) бирү механизмын, максатын һәм шартларын билгели.

Әлеге Тәртипне куллану максатларында сәнәгать парклары, технопарклар резидентлары дигәндә Татарстан Республикасының сәнәгать парклары һәм технопарклары территориясендә үз эшчәнлеген алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары аңлашыла.

Әлеге Тәртипне куллану максатларында комплекслы хезмәт күрсәтүләр дигәндә кластерларда катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шулай ук сәнәгать парклары, технопарклар резидентларына түбәндәге хезмәтләрдән торган ярдәм күрсәтү формасы аңлашыла:

читтән чакырылган экспертларның консультация хезмәтләре;

технологик әзерлек индексын экспресс-бәяләү буенча хезмәтләр;

импортны алмаштыру потенциалын бәяләү буенча хезмәтләр;

аудитлар һәм экспертизалар үткәрү хезмәтләре (финанс, идарә, техник, финанс-техник, технологик, энергетика, экология аудитларын һәм экспертизаларын һәм аларның башка төрләрен кертеп);

маркетинг хезмәтләре (маркетинг тикшеренүләрен уздыруны кертеп), Россия һәм халыкара базарларда продукциянең (товарларның, хезмәт күрсәтүләрнең) яңа төрләрен брендлау, позицияләү һәм этәрү хезмәтләре;

бизнес-планнар, техник-икътисадый нигезләүләр, инвестиция меморандумнары төзү хезмәтләре;

интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә һәм аларга тиңләштерелгән юридик затларны, товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне индивидуальләштерү чараларына хокукларны яклау хезмәтләре;

сертификатлаштыру (шул исәптән сыйфат менеджменты системасын) үткәрү, декларацияләү, лицензияләү һәм аттестацияләү хезмәтләре;

тикшеренүләр, сынаулар (шул исәптән лаборатория сынауларын) уздыру буенча хезмәтләр;

җитештерүне модернизацияләү, үстерү, техник яңадан коралландыру программаларын эшләү хезмәтләре;

үсеш һәм модернизация программаларын, инвестиция проектларын, коммерцияләштерү, импортны алмаштыру программаларын тормышка ашырганда, кризиска каршы чараларны, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм җитештерүне цифрлаштыру чараларын гамәлгә ашырганда эксперт булышлык күрсәтеп тору хезмәтләре;

техник чишелешләрне (проектларны, планнарны) эшләү, шул исәптән җитештерү процессларын цифрлаштыруны гамәлгә кертү хезмәтләре;

инженерлык-консультация, тәҗрибә-конструкторлык, сынау, инженер-тикшеренү, исәп-хисап һәм анализ хезмәтләре (шул исәптән яңа продуктларның тәҗрибә серияләрен эшләү һәм сынау буенча), проект-конструкторлык эшчәнлеге буенча хезмәтләр, шул исәптән конструкторлык, техник һәм технологик документацияне эшләү хезмәтләре;

Россия һәм чит ил күргәзмә-ярминкә чараларында, төбәк, төбәкара, гомумроссия һәм халыкара коммуникация чараларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының катнашуын оештыру хезмәтләре;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан үткәрелә торган семинарларда, стратегик сессияләрдә, түгәрәк өстәлләрдә, вебинарларда, тренингларда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының катнашуын оештыру хезмәтләре;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан үткәрелә торган форумнарда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының катнашуын оештыру хезмәтләре;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан үткәрелә торган төбәкара яки чит ил күчмә чараларында (бизнес-миссияләрдә) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының катнашуын оештыру хезмәтләре;

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары кадрларын әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү хезмәтләре.

Субсидия бирүнең максаты – кластерларда катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шулай ук сәнәгать парклары, технопарклар резидентларына комплекслы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле коммерциягә карамаган оешмалар чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау).

2. Субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен субсидия бирүгә бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Министрлык.

Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

3. Субсидияләр алучыларны сайлап алу Министрлык тарафыннан сайлап алуда катнашу өчен коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәрне (алга таба – заявка) сорау юлы белән, аларның сайлап алу критерийларына туры килүенә һәм заявкалар керү чиратына карап үткәрелә.

4. Заявка биргән айның 1 нче көненә коммерциягә карамаган оешма түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә коммерциягә карамаган оешма (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) буларак теркәлгән, Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясы нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларның бердәм реестрына кертелгән;

коммерциягә карамаган оешманы гамәлгә куючыларның берсе Татарстан Республикасы булу.

5. Субсидия заявка биргән айның 1 нче көненә түбәндәге таләпләргә туры килә торган коммерциягә карамаган оешмага бирелә:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау;

үзгәртеп оештыру (оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, коммерциягә кармаган оешманың эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процентган арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау.

6. Министрлык, заявкаларны кабул итә башлаган көнгә кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

әлеге Тәртипнең 17 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин итеп торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә коммерциягә карамаган оешмаларга карата таләпләрне һәм коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм әлеге Тәртипнең 7, 9 пунктлары нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага

үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 12 пункты нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

коммерциягә карамаган оешмаларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләрен аңлату тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогын;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасын;

әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә коммерциягә карамаган оешмаларны сайлап алу критерийларын.

9. Сайлап алуда катнашу өчен коммерциягә карамаган оешмалар сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокта Министрлыкка түбәндәге документларны үз эченә алган заявка тапшыра:

әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча коммерциягә карамаган оешма турында, бирелә торган заявка турында мәгълүматны, коммерциягә карамаган оешма турында башка мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга ризалыкны үз эченә алган субсидия бирүгә сайлап алуда катнашуга гариза;

гамәлдәге гамәлгә кую документларының күчермәләре;

заявка бирелә торган айның 1 нче көненә коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы өченче – алтынчы абзацларында каралган таләпләргә туры килүен раслый торган гарантия хаты;

коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан расланган әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар сметасы (финанс-икътисадый нигезләү кушымтасы белән, чыгымнар күләмен нигезләүче мәгълүматны, шулай ук аны алу чыганагын (товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләрнең счетлары, коммерция тәкъдимнәре, дәүләт статистикасы органнарында булган бәяләр дәрәҗәсе турында мәгълүмат, шулай ук, җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын да кертеп, массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта җитештерүче һәм тәэмин итүче мәгълүмат чараларында) күрсәтеп);

чыгымнарны каплауга гариза биргәндә әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча фактта башкарылган чыгымнарны раслый торган документлар (шартнамәләр һәм аларның кушымталары, түләү документлары (түләү йөкләмәләре, керем һәм чыгым ордерлары), локаль норматив актлар, аванс хисаплары, счетлар, универсаль тапшыру документлары, счет-фактуралар, башкарылган эшләр (күрсәтелгән хезмәтләр) актлары, накладнойлар).

7. Коммерциягә карамаган оешма үз теләге белән Министрлыкка түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият

кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын һәм аны электрон формада бирү форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча заявка бирелгән айның 1нче көненә иртәрәк бирелмәгән салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турында салым органының белешмә кәгазе;

«Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче, җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче яки салым агентының бердәм салым түләве сыйфатында күчерелгән акча суммасының кемгә каравы турында белешмә кәгазе формасын һәм аны электрон рәвештә бирү форматын раслау хакында» 2022 елның 30 ноябрендәге ЕД-7-8/1129@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча заявка бирү елының 1 гыйнварыннан заявка бирү аеның 1 нче көненә кадәр бирелгән салым түләүче, җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче яки салым агентының бердәм салым түләве сыйфатында күчерелгән акча суммасының кемгә каравы турында салым органының белешмә кәгазе;

заявка бирелә торган айның 1 көненнән дә иртәрәк булмаган датага бирелгән һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан әлеге пунктның сигезенче – унынчы абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге белешмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм (яки) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә ала.

8. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган расходлар (чыгымнар) юнәлешенә коммерциягә карамаган оешманың комплекслы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чит оешмалар һәм экспертлар хезмәтләре өчен түләү расходлары (чыгымнары), шул исәптән түбәндәгеләр керә:

чит экспертларның консультация хезмәтләре өчен, әмма бер эксперткa 400 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

технологик әзерлек индексына экспресс-бәя бирү хезмәтләре өчен, әмма бер кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына 250 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

импортны алмаштыру потенциалын бәяләү хезмәтләре өчен, әмма бер кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына 200 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

аудитлар һәм экспертизалар үткәрү хезмәтләре (финанс, идарә, техник, финанс-техник, технологик, энергетика, экология аудитларын һәм экспертизаларын һәм аларның башка төрләрен кертеп) өчен, әмма бер кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына 500 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

маркетинг хезмәтләре (маркетинг тикшеренүләрен уздыруны кертеп), Россия һәм халыкара базарларда продукциянең (товарларның, хезмәт күрсәтүләрнең) яңа төрләрен брендлау, позицияләү һәм этәрү хезмәтләре (сайтлар ясау һәм модернизацияләүне, видеороликлар һәм полиграфия продукциясе эшләү һәм әзерләүне, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә таратуны, сатып алуларда катнашу процедурасында комплекслы булышлык күрсәтүне, программа

продуктларыннан (шул исәптән электрон-мәгълүмат системаларыннан файдалану мөмкинлеген бирә торган программа продуктларыннан) файдалануга чикләнгән хокуклар сатып алуны кертеп) өчен, әмма бер кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына 400 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

бизнес-планнар, техник-икътисадый нигезләүләр, инвестиция меморандумнарын эшләү өчен, әмма бер кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына 450 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә һәм аларга тиңләштерелгән юридик затларны, товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне индивидуальләштерү чараларына хокукларны яклау хезмәтләре (патент тикшеренүләре үткәрү, патент эзләнүләр, Россия һәм халыкара базарларда интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә (патентларга һәм товар билгеләренә) хокукларны теркәүгә заявкалар әзерләү һәм бирүне кертеп ) өчен, әмма бер кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына 500 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

сертификатлаштыру (шул исәптән сыйфат менеджменты системасын) үткәрү, декларацияләү, лицензияләү һәм аттестацияләү хезмәтләре өчен, әмма бер кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына 650 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

тикшеренүләр, сынаулар (шул исәптән лаборатория сынауларын) уздыру буенча хезмәтләр өчен, әмма бер кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына 550 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

җитештерүне модернизацияләү, үстерү, техник җиһазландыру программаларын эшләү хезмәтләре өчен, әмма бер кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына 800 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

үсеш һәм модернизация программаларын, инвестиция проектларын, коммерцияләштерү, импортны алмаштыру программаларын тормышка ашырганда, кризиска каршы чараларны, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм җитештерүне цифрлаштыру чараларын гамәлгә ашырганда эксперт булышлык күрсәтеп тору хезмәтләре өчен, әмма бер кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына 300 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

техник карарлар (проектлар, планнар) эшләү, шул исәптән җитештерү процессларын цифрлаштыруны гамәлгә кертү хезмәтләре өчен, әмма бер кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына 800 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

инженерлык-консультация, тәҗрибә-конструкторлык, сынау, инженерлык-тикшеренү, исәп-хисап һәм анализ хезмәтләре (шул исәптән яңа продуктларның тәҗрибә серияләрен эшләү һәм сынау буенча), проект-конструкторлык эшчәнлеге буенча хезмәтләр, шул исәптән конструкторлык, техник һәм технологик документацияне эшләү хезмәтләре өчен, әмма бер кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына 800 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

Россия һәм чит ил күргәзмә-ярминкә чараларында, төбәк, төбәкара, гомумроссия һәм халыкара коммуникация чараларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының катнашуын оештыру хезмәтләре (күргәзмә мәйданнарын һәм җиһазларын арендалауны, оештыру, теркәү кертемнәре өчен түләүне, оештыру чыгымнарын, стенд, күргәзмә экспозициясен, бүлмәләрне ясау, шул исәптән стенд, күргәзмә экспозициясен, бүлмәләрне монтажлау һәм сүтүне, стенд, күргәзмә экспозициясе, бүлмәләрнең декорация-техник бизәлеше өчен түләү, презентация

материалларын тәрҗемә итүне, транспорт хезмәтләрен, тәрҗемәче хезмәтләрен кертеп) өчен, әмма бер Россия чарасына 1 млн.сумнан һәм бер чит ил чарасына 1,5 млн.сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан үткәрелә торган семинарларда, стратегик сессияләрдә, түгәрәк өстәлләрдә, вебинарларда, тренингларда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының катнашуын оештыру хезмәтләре (шул исәптән семинарлар, стратегик сессияләр, түгәрәк өстәлләр, вебинарлар һәм тренинглар оештыру һәм үткәрү (бүлмәләр һәм җиһазлар арендалауны, туклandыруны оештыру, транспорт хезмәтләре, тәрҗемәче хезмәтләре, түләүле нигездә спикерлар һәм экспертларны җәлеп итү, оештыру чыгымнары, чыгым материаллары, шул исәптән тарату материаллары сатып алу, полиграфия, сувенир, реклама һәм мәгълүмат-аналитик продукция әзерләү, навигация чаралары, табличкалар, элмә такталар, баннерлар һәм стендлар ясау һәм урнаштыруны кертеп) өчен, шул исәптән дизайн, макетлар эшләү өчен, әмма бер чарага 300 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан үткәрелә торган форумнарда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының катнашуын оештыру хезмәтләре (форумнар оештыру һәм үткәрү (бүлмәләр һәм җиһазлар арендалауны, туклandыруны оештыру, транспорт хезмәтләре, тәрҗемәче хезмәтләре, түләүле нигездә спикерлар һәм экспертларны җәлеп итү, оештыру чыгымнары, чыгым материаллары, шул исәптән тарату материаллары сатып алу, полиграфия, сувенир, реклама һәм мәгълүмат-аналитик продукция әзерләү, навигация чаралары, табличкалар, элмә такталар, баннерлар һәм стендлар ясау һәм урнаштыруны кертеп) өчен, шул исәптән дизайн, макетлар эшләү өчен, әмма бер форумга 2 млн.сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан үткәрелә торган төбәкара яки чит ил күчмә чараларында (бизнес-миссияләрдә) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының катнашуын оештыру хезмәтләре (бизнес-миссияләр оештыру һәм үткәрү (бүлмәләр һәм җиһазлар арендалауны, туклandыруны оештыру, транспорт хезмәтләре, тәрҗемәче хезмәтләре, оештыру чыгымнары, чыгым материаллары, шул исәптән тарату материаллары сатып алу, полиграфия, сувенир, реклама һәм мәгълүмат-аналитик продукция әзерләүне кертеп) өчен, шул исәптән дизайн, макетлар эшләү өчен, әмма бер чарага 700 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар);

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары кадрларын әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү хезмәтләре өчен, әмма бер кешегә 300 мең сумнан артмаган расходлар (чыгымнар).

9. Документлар коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан кәгазьдә һәм электрон мәгълүмат саклагычта тапшырыла.

Кәгазьдә тапшырылган барлык документлар аңлаешлы итеп бастырып чыгарылган булырга тиеш. Коммерциягә карамаган оешманың мөһере (булганда) сугылган һәм коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе яки аның вәкаләтле заты имзасы белән расланган төзәтмәләрдән тыш, чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми. Кәгазьдә бирелгән заявканың барлык битләре номерланган булырга тиеш. Кәгазь чыганакта бирелгән заявка тегелгән һәм аңа коммерциягә карамаган оешма җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның имзасы куелган һәм коммерциягә

карамаган оешманың мөһере сугылган, заявканың арткы өлешендә битләрнең гомуми саны күрсәтелгән булырга тиеш.

10. Министрлык заявкаларны теркәү журналында заявкаларны алу датасы һәм вакыты күрсәтелгән көннән алып бер көн эчендә кабул итә һәм терки. Заявкага, аның Министрлыкка керү чиратына карап, тәртип номеры бирелә. Заявкага үзгәрешләр кертү аны теркәгәннән соң рөхсәт ителми.

11. Коммерциягә карамаган оешмалар заявкаларны кабул итү тәмамланган датага кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Заявкалар кабул итү тәмамланган датадан соң заявканы кире алу рөхсәт ителми.

12. Министрлык заявкаларны кабул итү тәмамланган көннән алып биш эш көне эчендә коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тапшырылган заявканы һәм документларны әлеге Тәртипнең 7, 9 пунктларында каралган таләпләргә туры килүне һәм коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында каралган таләпләргә һәм критерийларга туры килүен карап тикшерә.

Министрлык әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срок тәмамланган көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча сайлап алу җиңүчеләрен билгели һәм субсидия бирү яисә заявканы кире кагу турында карар кабул итә.

Заявканы алудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

заявкалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң заявка бирү;

коммерциягә карамаган оешма әлеге Тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

коммерциягә карамаган оешма әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган сайлап алу критерийларына туры килмәү;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән мәгълүмат, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүмат дөрес булмау.

13. Министрлык, әлеге Тәртипнең 12 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән срок тәмамланган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе бюджет системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталында һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра, анда түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

килешү төзелә торган субсидия алучыларның исемнәре һәм аларга бирелә торган субсидиянең күләме.

14. Чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) ($С_{фо}$) субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_{фо} = P_1 + P_2 + P_3 + \ldots + P_n,$$

монда $P_1$, $P_2$, $P_3$, …, $P_n$ – әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча бирелә торган субсидия исәбеннән финанс белән тәэмин ителергә тиешле комплекслы хезмәтләр өчен түләү чыгымнары.

Әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча субсидия исәбеннән финанс белән тәэмин ителергә тиешле чыгымнар Министрлык тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән, шулай ук әлеге Тәртипнең 7 пунктындагы бишенче абзацы нигезендә тапшырылган документларны исәпкә алып билгеләнә һәм әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән һәр хезмәт өчен түләү чыгымнарының иң чик күләмнәреннән артмаска тиеш.

Чыгымнарны каплау өчен субсидия күләме ($C_{вз}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_{вз} = З_1 + З_2 + З_3 + \ldots + З_n,$$

монда $З_1$, $З_2$, $З_3$, …, $З_n$ – әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча коммерциягә карамаган оешма тарафыннан фактта башкарылган чыгымнар.

Әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча субсидияләр исәбеннән капланырга тиешле чыгымнар Министрлык тарафыннан әлеге Тәртипнең 7 пунктындагы алтынчы абзацы нигезендә тапшырылган документлар нигезендә, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлау юлы белән билгеләнә торган бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләреннән артмаган һәм әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән һәр хезмәт өчен түләү чыгымнарының иң чик күләменнән артмаган, фактта башкарылган чыгымнардан чыгып билгеләнә.

15. Министрлык тарафыннан Министрлык һәм субсидия алучы арасында субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча килешү төзелә.

Әгәр субсидия алучы килешүгә бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокта кул куймаган булса, ул килешү төзүдән баш тарткан дип санала.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);

субсидияне күчерү сроклары һәм тәртибе;

өстәмә хисап бирү сроклары һәм формалары (кирәк булганда);

субсидияне кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

әлеге Тәртипнең 20 пунктында билгеләнгән формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен куллану очракларын күздә тоткан шартлар;

субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Россия Федерациясе бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алуны тыю турында нигезләмә (чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен субсидия алганда);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, Министрлык тарафыннан әлеге Тәртипнең 21 пунктында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда әлеге акчага ихтыяҗ булу яки әлеге акчага ихтыяҗ булмаганда аларны кире кайтару турында карар кабул ителгәндә, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеге каралган шарт;

субсидия алучының, субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) Министрлык тарафыннан аларга карата субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы (чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия алганда);

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары Министрлыкка киметелгән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында, субсидияне килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин булмавына китерә торган шарт.

16. Кирәк булуга карап, Министрлык һәм субсидия алучы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

17. Субсидия бирү нәтиҗәсе – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына күрсәтелгән хезмәтләр саны (берәмлек). Субсидия бирү нәтиҗәсен исәпләп чыгарганда кластерларда катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шулай ук сәнәгать парклары, технопарклар резидентларына әлеге Тәртипнең 1 пункты нигезендә комплекслы хезмәтләр составында күрсәтелгән хезмәтләр исәпкә алына.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү срогы – субсидия бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

Субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткече килешүдә билгеләнә.

18. Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Министрлык субсидия алучының Россия Федерациясе Үзәк банкы яисә кредит оешмалары учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетына күчерә.

Субсидия алучы субсидия акчасының керүе һәм тотылуы буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

Чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия алганда субсидия алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүләрнең бертип формаларына теркәлә торган формалар буенча финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешү турында хисап (раслый торган документларны теркәп) кертә.

Чыгымнарны каплауга субсидия алганда субсидия алучы, килешү имзаланган көннән соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешү турында хисап (раслый торган документларны теркәп) кертә.

19. Субсидия алучы бирә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидияләрдән максатчан файдаланылмау өчен законнар нигезендә җавап бирә.

20. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланганда; субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булганда; әлеге Тәртипнең 18 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән срокта субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткече турында хисап, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап (чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия алганда); әлеге Тәртипнең 18 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән срокта субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешү турында хисап тапшырмаган очракта (чыгымнарны каплауга субсидия алганда);

максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган күләмдә – субсидия акчасы максатчан файдаланылмаган очракта.

Әгәр субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгән булса, Министрлык субсидия алучыга карата штраф санкцияләрен куллану турында карар кабул итә, субсидия алучыга әлеге карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә мәҗбүри рәвештә хәбәр итә.

Штраф санкцияләре күләме (A) әлеге очракта түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$A = \left(1 - \frac{d}{D}\right) \times X \times V,$$

монда:

d – килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсенең ирешелгән күрсәткече;

D – килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча күрсәткече;

X – хисап кварталының соңгы көне хәленә карата Россия Федерациясе Үзәк банкының төп ставкасына тигез булган төзәтү коэффициенты;

V – субсидия алучы тарафыннан алынган субсидия акчасының күләме.

21. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш (чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия алганда).

Хисап финанс елында файдаланылмаган юнәлешләргә ихтыяҗ булган очракта, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидия алучы Министрлыкка хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча шундый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Министрлык, субсидия алучыдан бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, бюджет законнары нигезендә субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу яки булмау турында карар кабул итә.

Министрлык тарафыннан субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык һәм субсидия алучы арасында мондый карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә килешүгә өстәмә килешү төзелә.

22. Әлеге Тәртипнең 20 һәм 21 пунктларында күрсәтелгән субсидияне, субсидиянең калган өлешләрен кире кайтару сроклары бозылган очракларда, Министрлык субсидияне, субсидиянең калган өлешләрен кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә әлеге акчаны Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

23. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән әлеге Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

24. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

25.Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.

Кластерларда катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шулай ук сәнәгать парклары, технопарклар резидентларына комплекслы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры

_____________________________ га

Кластерларда катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шулай ук сәнәгать парклары, технопарклар резидентларына комплекслы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирүгә сайлап алуда катнашуга
гариза

______________________________________________________________________
(коммерциягә карамаган оешманың исеме)
____________________________________________________________ нигезендә эш итүче
__________________________________________________________________ йөзендә,
(вазыйфасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кластерларда катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шулай ук сәнәгать парклары, технопарклар резидентларына комплекслы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» ______, ___________, _____ нчы карары белән расланган Кластерларда катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы кече

һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шулай ук сәнәгать парклары, технопарклар резидентларына комплекслы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) нигезендә кластерларда катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шулай ук сәнәгать парклары, технопарклар резидентларына комплекслы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия алуга сайлап алуда катнашу (устав, нигезләмә, ышанычнамә) өчен документлар җибәрә.

Моның белән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә коммерциягә карамаган оешма турында, аның тарафыннан бирелгән гариза турында мәгълүмат, сайлап алуга бәйле коммерциягә карамаган оешма турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгымны бирәм.

Тәртипнең 5 пунктындагы 4 пунктында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килүне, шулай ук заявка составында тапшырылган документларның дөреслеген раслыйм.

Тәртип шартлары белән таныштым һәм тулысынча килешәм.

Теркәлә торган документлар исемлеге:
1.
2.
3.
...

Җаваплы зат _____________________________________
(Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

Элемтәгә керү өчен телефон: _________________________

Коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе ______________________ _________
(Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булган очракта)) ( имза)

м.у.

Дата ___________________

___________________